1789 елда император Екатерина II указы буенча Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя оештырылуның максаты, мәхәлләләргә билгеләнә торган дин әһелләреннән имтихан алу аша, хөкүмәткә лояль, халыкның Урта Азия һәм Госманлы дәүләтләренең идеологиясенә иярмәвен, татар, башкорт муллаларының сәяси өлкәгә кысылмауларын, мөселманнар хакимияткә каршы баш күтәргән очракта, аларда катнашмый һәм социаль протестны әйдәми, киресенчә, җәмәгать тынычлыгын тәэмин итә торган, дин әһелләре булдыру белән билгеләнә. Шуңа да дәүләт оешмасының рәисе булган мөфтинең хокукый дәрәҗәсе киметелә, аның фәтвалары канун көченә ия булмый. Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя карарлары коллегиаль рәвештә мөфти һәм Казан губернасы муллалары үзләре арасыннан 3 елга сайлап куелган өч казый белән берлектә киңәшеп кабул ителә. Нәтиҗәдә, «мөфти – мөселманнарның дини башлыгы» дигән гыйбарәнең мәгънәсе югалып, бары тик яңгыравык исем генә булып кала.

XIX гасырның беренче яртысында, бигрәк тә дәүләт белән император Николай I идарә иткән дәвердә, Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыянең хокуклары киңәя башлый. Дәүләт оешмасы булуга карамастан, ул чын мәгънәсендә Идел, Урал һәм Көнбатыш Себер төбәге дини институтларының җитәкчесенә әверелеп, мөселман приходларының, дин әһелләренең мәнфәгатьләрен хакимият алдында яклаучы оешмага әверелә. Бу үзгәрешләр үзәк «фатихасы» белән башкарыла: теократик хөкүмәт, күбәеп барган мәчетләр, дин әһелләре, мәктәпләр, илдәге башка оешмалар өстеннән урнаштырылган контрольне Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя аша үзәкләштерергә омтылып, аның хокукларын киңәйтә. Әйтик, 1801 елдан башлап губерна идарәләре яңа мәчет төзергә яисә яңа приходны теркәргә рөхсәт алу кебек эшләрне Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя белән килештереп башкару тәртибе урнаша, 1811 елдан муллалар гаилә мөнәсәбәтләренә караган мәсьәләләрне рәсми тикшерү һәм карар чыгару хокукы ала, 1828 елдан Мәхкамә-и

шәргыя Ырынбургыягә һәм имамнарга приходта гражданлык актларын теркәү өчен метрикә кенәгәләрен алып бару, аларны саклау һәм нотариус кебек төрле справкалар бирү йөкләнә, 1836 елдан мөселманнарның мирасын бүлү шәригать кануннары буенча тормышка ашырыла башлый һ.б. [1: 7].

Рәсми документларларда Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя (русча: Оренбургское магометанское духовное собрание) дип атасалар да, чынлыкта ул, мөселман илләрендәге шәригать мәхкамәләре кебек, тикшерүгә шаһитларны, гаепләнүчене һәм зыян күрүчене чакырып карар чыгару кебек эшләр башкармый, фәкать шикаятьләрне, гаризаларны кабул итә, аларны, урында өйрәнү максатында, төбәктәге берәр ахунга яки гыйлемле һәм гаделлеге белән танылган имамга юллап, үзе читтән күзәтеп тора, бюрократик оешма буларак, күп очракларда килгән хатларны, карар кабул итү өчен, губерна идарәсенә адреслый һәм тикшерү нәтиҗәсен соратып ала. Шунысын да әйтеп узу мөһим: Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя округына кергән төбәкләрдә мөселманнарга карата шәригать буенча җәза куллану тыела, җинаятьчеләргә җәза билгеләү – дәүләт мәхкамәләре, ә вак канун бозулар волость идарәсе мәхкамәсе карамагына бирелә [2: 174].

Аграр Россиядә татарларның һәм башкортларның хакимият тарафыннан рөхсәт ителгән мөселман приходлары кысаларында үзләренең рухи һәм мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү системасы – дини-мәдәни автономия формалаша. Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя – Идел, Урал һәм Көнбатыш Себер төбәгендәге ислам дини институтлары өстеннән күзәтчелек һәм идарә итүче хөкүмәт оешмасы – мөселманнар дини-мәдәни автономиясенең башы булып, XIX гасыр азагында үзен мөселман җәмгыятенә яңарыш кирәклеге турындагы фикерләрне таратучы оешма буларак таныта башлый.

Хакимият 1886 елны мөфти итеп Казан гимназиясен тәмамлаган, бер ел университетта укып, сәламәтлеге начар булу сәбәпле, укуын калдырган, урта кул чиновник дәрәҗәсенә ирешкән морзалардан (дворян) Мөхәммәдъяр Солтановны билгели.

Русча белем алган, ләкин татарчасы чамалы булган мөфти, казыйларның дәүләт телен начар белүләренә, шәригать өлкәсендә белемнәренең йошмак булуына тирән борчылып, яңа буын муллалары русча укый-яза белергә тиеш дигән ныклы фикергә килә, булачак казыйларның белем дәрәҗәләре Татар укытучылар мәктәбен яки өяз башлангыч училищесын тәмамлаучыларныкы кебек, ә шәһәр мәхәлләләре ахуннары һәм имамнары, шулай ук регуляр һәм казак гаскәрендәге муллалар башлангыч халык училищеларын тәмамлаучылар дәрәҗәсендә булырга тиеш дип, эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итә [3: 5-7]. Моңарчы мөселман дин әһелләренә русча белүне мәҗбүри итәргә теләп төрле проектлар корган хөкүмәт бу фикерне күтәреп ала, ләкин аның мәгънәсен бозып, «киңәйтеп һәм тирәнәйтеп», 1888 ел 16 июль канунын кабул итә [4: 242-245]. Аның буенча, 1891 елдан башлап Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыянең казые булырга теләүчеләр Татар укытучылар мәктәбе яки рус гимназиясенең 4 сыйныфы, яки өяз, шәһәр ике сыйныфлы башлангыч мәктәбен тәмамлаучылар дәрәҗәсендә, ахун һәм шәһәрдә имам булырга теләүчеләр – бер сыйныфлык халык училищелары, авыл имамнары – өяз училищелары советларында русча сөйләшә һәм укый алулары турында имтихан тотарга тиеш булалар [5]. Мөфтинең проекты казыйларга һәм азсанлы шәһәр имамнарына гына кагылган булса, 1888 ел 16 нчы июль кануны русча белүне барлык булачак имамнарга мәҗбүри итеп куя.

Бу яңалыкка каршы мөселманнарның императорга, эчке эшләр министрлыгына адресланган меңнән артык протест гаризалары хакимиятне, канунны үзгәртеп, булачак казыйларга таләпләрне киметергә мәҗбүр итә: аларның гыйлем дәрәҗәсе русча укый-яза белү белән чикләнә (1896 елдан шәһәр училищесын тәмамлау таләбе куела) [6]. Шулай итеп, мөфти М.Солтанов кадимче муллаларның иң олы дошманына әйләнә. Ләкин тормыш үзенекен итә: 1891 елдан булачак имамнар, шул исәптән русча уку Коръәндә тыелган дигән фикерне яклаган кадимчеләрнең уллары һәм туганнары да тиешле имтиханны бирә башлыйлар. Булачак муллаларга русча белем цензын кулланып, хөкүмәт ислам дини укыту һәм тәрбия системасын җимерергә тели дип шөбһәләнгән татар байлары да, карашларын үзгәртеп, 1896 елда М.Солтанов белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыралар: мөфти узып барышлый Казанда тукталгач, шәһәр биржасы бинасында, хакимият вәкилләрен чакырып, аның хөрмәтенә аш мәҗлесе уздыралар [7].

Мондый уңай үзгәрешләрнең сәбәбе, беренчедән, Казан сәүдәгәрләренең

җәдитчелеккә йөз белән борылуы булса, икенчедән, мөфтинең дә җәдитчеләр яклы булып, ул Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыйдә башлаган реформалар була. Әйтик, 1890 ел 9 нчы гыйнвар кануны нигезендә М.Солтанов, казыйлыкка кандидатны үзе сайлап алып, раслау өчен, эчке эшләр министрына тәкъдим итү хокукы ала [8]. Шулай үз тирәсенә яңалыкка омтылучы, милләт өчен җан атучы, китаплар язу белән мавыгучы иҗади шәхесләрне, алдынгы карашлы, шәригать кануннарын яхшы белүче һәм Россия тормышыннан хәбәрдар булган гыйлемле яшьләрне җыя. Мәхкамә-и шәргыя 2-3 ел эчендә алгарыш яклы гыйлемле дин әһелләре тупланган үзәккә әверелә.

1891 елны Уфага Самара губернасы Бөгелмә өязе Илбәк авылы имамы мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдин гаиләсе белән күченеп килә һәм 1906 елга кадәр, бертуган Рәмиевләр чакыруы буенча «Вакыт» газетасын оештыру һәм нәшер итү өчен Оренбург каласына киткәнче, казый буларак зур эшләр башкарырга өлгерә. 1893 елда казый итеп Пенза губернасы Инсар өязеннән ахун Гыйниятулла Капкаев чакырыла һәм дистә елдан артык шушы вазифаны уңышлы үтәп килә [8: 146-158]. 1892-1895 елларда казый булып Тара шәһәре ахуны, булачак күренекле җәмәгать эшлеклесе, «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыручыларның берсе Габдеррәшит Ибраһимов хезмәт итә.

Габдеррәшит Ибраһимовны Казан өязе Кече Солабаш авылында имам булып торучы Хәсәнгата Габәши (1863-1936) алыштыра. Хәсәнгата 1874-1886 елларда Әҗем мәчете каршындагы «Гаффария» мәдрәсәсендә укый. Укуының соңгы 5 елында хәлфәлек итә. Үзлегеннән, шәһәр мөмкинлекләрен файдаланып, рус телен өйрәнә, хисап, география, геометрия, табигать, тарих өлкәләрендә мөмкин булган юллар белән гыйлем эстәргә тырыша. Аның дөньяга карашы формалашуда һәм системалы белем туплавын тәэмин итүдә Казан каласында яшәп иҗат иткән күренекле шәхесләр, галимнәр белән аралашу да мөһим роль уйный. Сүз, беренче чиратта, татар мәгърифәтчеләре, гыйлем ияләре Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Гали Мәхмүдов, Шаһбазгәрәй Әхмәрев, Галимҗан Баруди, шулай ук университет галимнәре Иосиф Готвальд, Николай Катанов һәм башкалар турында бара. Исмәгыйль Гаспралы белән очрашу, фикер алышу да аның дөньяга карашын киңәйтеп җибәрә. 1889 елдан ул Казан сәүдәгәрләре бертуган Юнысовларның мөселман балалар ятимханәсе мәктәбенә эшкә урнаша, биредә 1891-1892 уку елларында, шәһәрдә беренчеләрдән булып, укырга өйрәтүдә аваз ысулын (ысулы саутия, ысул җәдит) куллана. Бер үк вакытта 1890 елдан туган авылында имам-хатыйб вазифасына керешә. 1893-1894 елларда үз йортында мәктәп ачып, җәдит ысулы белән укытуны җайга сала, соңрак дәресләр сәүдәгәр Әхмәт Хөсәенев салып биргән заманча мәктәп бинасында дәвам итә. Х.Габәши, Уфага күченеп килгәнче, берничә китап язып, мөселманнар арасында танылу ала [10: 195].

Казыйлар Р.Фәхретдин һәм Х.Габәшинең фикердәшләр, мәсләктәшләр булуы Мәхкамә-и шәргыянең эшчәнлегенә яңа сулыш өреп генә калмый, сыйфат ягыннан да зур үзгәрешләргә китерә. Хәсәнгата Габәшинең оештыру сәләте, Ризаэтдин Фәхретдиннең максатчан рәвештә Мәхкамә-и шәргыянең архивын, дистә еллар дәвамында җыелып яткан эш кәгазьләрен тәртипкә салуы, аларның бер-берсен тулыландырып эшләве матур нәтиҗәләр биргән. Ике мәгърифәтче, дини идарәнең административ ресурсын төрле юллар аша файдаланып, мөселманнарны алгарышка алып баруда төп фигура дип уйланылган муллаларның хезмәтен җиңеләйтү өчен зур тырышлык куялар. 1890 елларда күпсанлы инструкцияләр, аңлатулар аша көндәлек тормышта яки хакимият органнары белән мөнәсәбәттә аларга кыенлык тудырган сорауларга җаваплар әзерләп бастыралар, дини йолалар (ритуаллар) һәм социаль мәсьәләләрдә, дәүләт тарафыннан йөкләнгән вазифаларын җиренә җиткереп башкару өчен, хокукый җирлек булдырырга омтылалар. Әйтик, имамнарга, метрикәләрдән мәгълүмат сорап мөрәҗәгать итүчеләргә бирер өчен, кешеләрнең туган, үлгән вакыты, гаилә хәле һ.б. турында справка үрнәкләре, метрикә күчермәләре бланклары, кергән һәм бирелгән документларны теркәү реестрлары, мәхкамәдә гаепләнүчеләргә яки шаһитларга ант бирү текстлары, милек бүлү акты формалары эшләнә, вакыфларны файдалану турында кагыйдәләр төзелә һ.б. [11: 214-221].

Җәмгыятьтә башланган яңарышны киң мәйданга алып чыгып, аны чын мәгънәсендә иҗтимагый күренешкә әйләндерү өчен, аңа мөселман дин әһелләрен җәлеп итү мөһим була, чөнки яңа фикерләрне һәр торак пунктында

тарату алар рөхсәте һәм катнашында тормышка ашырыла. Башланган үзгәрешләр чорында мәхәлләләрдә алдынгы фикерле, яңалыкка йөз белән борылган имамнарның төп фигура булулары ачык күренә. И.Гаспралы бу хакта «Тәрҗеман-Переводчик» газетында еш яза. Аның фикеренчә, гыйлемле, намуслы, югары әхлакка ия булган мулла үзенең мәхәлләсенә гаять зур файда китерә ала. Ул мөгаллим дә, киңәшче дә, хокук белгече дә, дәгъватче дә, үзенең мисалында әхлаклы көнитеш үрнәген гәүдәләндерүче дә. Мөгаллим буларак, аң-белем тарата, дәгъватчы буларак, мөселманнарны югары әхлакка һәм тырыш хезмәткә корылган тормыш алып барырга өнди, һәм шундый яхшы тормыш үрнәге күрсәтә, ул кешеләрне яңарышка, прогресска алып бара, хокук белгече һәм казый буларак, дин кардәшләре арасындагы ызгышларны, каршылыкларны киметә, хокукны өстен куеп, тәртип урнаштыра. Бер сүз белән әйткәндә, мулла һәм дин галименең эшчәнлеге бик киң. Алар халыкны яхшылыкка да, бер үк вакытта рухи һәм матди юкка чыгуга да алып бара ала [12].

И.Гаспралы фикерләре белән танышу, Р.Фәхретдин, Г.Ибраһимов, Х.Габәши, татар буржуазиясе вәкилләре белән аралашу 1897 елда мөфти М.Солтановны милләт хадиме булачак чыгыш ясарга, мөселманнарның тормышына һәм киләчәгенә карата үзенең гражданлык позициясен анык белдерүгә этәрә. Кунакка чакырган күренекле татар сәүдәгәрләре мәҗлес вакытында имамнарны яңача укытуга үгетләү турында үтенеп сорасалар да, гадәттә бер сүз дә сөйләмичә, мондый сөйләшүләрдән кача торган мөфти М.Солтанов [13: 137] чынлыкта аерым кешеләр белән аралашканда, шәхси хатларында җәдитчә укытуны яклап чыккан [14: 20]. Мөфти һәм казыйлар белән якыннан аралашкан сәүдәгәр Габделгани Хөсәенев үзенең 1898 елның февраль ае башында яздырган бер хатында, җәдитчә укыту өлкәсендә Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя белән кадимче муллалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләргә ишарәләп: «Туры әмернамә язарга куркалар. Мөфти дә яза алмый. Хат белән «иҗтиһад кылыгыз», дип үгет-юлы белән язгаладылар», дип белдерә [14: 36]. Шундый катлаулы шартларда, гражданлык батырлыгы күрсәтеп, М.Солтанов 1897 елны имамнарга, мөдәррисләргә, мөгаллимнәргә, мөәзиннәргә һәм ахуннарга махсус нәсыйхәт белән мөрәҗәгать итә, аның тексты русча һәм татарча бастырылып, барлык мәхәлләләргә таратыла. М.Солтановның 1897 ел 6 нчы сентябрь нәсыйхәтенең төп лейтмотивы булып, һәр мөселман, гаилә башлыгымы ул, гади игенчеме, мулламы, битарафлыктан качып, аңа йөкләгән бурычларына карата җаваплырак булырга, җәмгыять эшләрендә активрак катнашырга чакыру фикере тора дисәк, ялгышмабыз. Биредә шуны искәртеп үтү урынлы булыр: беренчедән, имамнарга Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыянең әмернамәсен үтәү мәҗбүри, фарыз булса, мөфтинең нәсыйхәтнамәсе киңәш характерында була, икенчедән, 1874 елда мәктәп-мәдрәсәләр өстеннән күзәтү Халык мәгарифе министрлыгына тапшырылганнан соң, Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыянең мәктәп-мәгариф өлкәсендә сүз әйтергә рәсми хокукы булмый.

М.Солтанов үзенең нәсыйхәтнамәсендә дин әһелләре игътибарын берничә мәсьәләгә юнәлтә. Беренчедән, мәчетләрне тиешенчә карап тоту зарурлыгына туктала, чөнки гыйбадәт йортларының тышкы кыяфәте мөселманнарның исламга мөнәсәбәтенең, аны хөрмәтләүләренең анык дәлиле, ди ул. Мөфти, ел дәвамында гыйбадәт кылу урыны булып хезмәт итәрлек төзек, җылы һәм яктыртылган мәчетләрне тотуны һәм дини кагыйдәләр, һәм дәүләт кануннары куша, дип ассызыклый. Мәчетләрнең уты һәм шәмнәре һәрвакыт булып торсын, тәрәзә һәм пыялалары, мич һәм морҗалары нык һәм төзек булсын, идәннәре юылган һәм тузансыз булсын, намазлыклары җыерылып һәм тузылып тормасын, һавасы яхшы һәм йомшак булсын дип бераз вакланып китеп, ахырда гыйбадәт урыны никадәр хуш булса, шул кадәр хозур булачагы мәгълүмдер дип, йомгак ясап куя. М.Солтанов имамнарны нинди очракларда яңа мәчет төзергә, ремонтларга яки үзгәртеп корырга рөхсәт ителү турындагы Россия кануннары белән дә таныштырып китә [15: 101].

Икенче мөһим бурыч итеп, һәрбер ата баласына һәм вәлиләләр (опекуннар) үзләренең карамагында булган балаларга белем бирергә һәм күркәм холык тәрбияләргә тиешләр дип искәртә. Шуның өчен алар ир һәм кыз балаларга дин кагыйдәләрен өйрәтү, яхшыны начардан аеру, яхшы холык һәм күркәм гадәтләрне тәрбияләү өчен укытырга тиеш булуларын имамнарга аңлатырга куша. Мәхәллә мәктәпләренең яхшы, мәктәп-мәдрәсәләрнең тузан, дым, ис кебек зарарлы

нәрсәләрдән саф булуын тәэмин итү, ягъни балаларга белем алырга тиешле шартлар тудыру һәм кайгырту мәхәллә халкының бурычы дип белдерә. Мөфтинең мөгаллим, мөдәррисләр тормышта файда китерә торган белемнәрне укытырга тиеш, шулай ук шәкертләрнең аеруча дөрес язу һәм күркәм язу белеменә зур әһәмият бирү фарыз диюе игътибарны җәлеп иткән яңа фикер була.

Өченче итеп, мөфти мәрхүмнәрне, ата-аналарыбызның яткан урыннарын – каберләрен хөрмәтләү кирәклеккә басым ясый. Аларны изге гамәл кылып, тәрбияләп, каберләрне хайваннар таптамасын өчен, зыяратларның тирәсен коймалап алу, чит-читләреннән чокыр казуны мәхәллә халкының бурычы икәнен искәртә [15: 102].

Нәсыйхәтнамәдә төп урын имамнарның җәмгыятьтәге рольләренә һәм бурычларына, аларга бу дөньяда йөкләнгән миссиягә бирелгән. Мөфти имамнарны, мөселман өммәтенә бу дөньяда һәм ахирәттә юл күрсәтү өчен, Аллаһы тәгалә тарафыннан җибәрелгән Мөхәммәд пәйгамбәрнең эшен дәвам итүче, аның юлын саклап, халыкка күрсәтеп торучы һәм заман белән бергә атлаучы галимнәргә тиңли. Безнең заманның галимнәре исә мәхәллә имамнары, шуңа күрә шәригать хөкемнәрен белдереп, халыкка вәгазь итегез, ди. Ата-анага итагать кылу, балаларга шәригать кушканча тәрбия бирү, хатыннар һәм ирләр арасында, гаиләдә бер-береңне ихтирам итүгә корылган мөнәсәбәтләр булдыру, мөселманда кардәшен күреп, башка милләт кешесен дус санап, килешеп-аңлашып яшәү; ялкауланмыйча, кәсеп һәм һөнәрләр үзләштерү зарурлыгының иң беренче дәрәҗәдә мөһим икәнен, вакытын һәм урынын белеп, һәм Коръән, һәм хәдисләргә нигезләп вәгазьләгез, гарәп һәм фарсы сүзләрен катыштырмыйча, гади халык аңлый торган телдә ачык сөйләгез дип искәртә. Үзләренең фикерләре күркәм булган кешеләрнең вәгазьләре һәм әсәрләре уңышлы булуы мәгълүмдер, шуңа күрә имамның мөнбәрдән сөйләгән сүзләре белән кылган гамәлләре туры килгән очракта гына вәгазь кеше күңеленә барып җитәр дип кисәтеп, имамнар күркәм холыклы һәм дин кагыйдәләрен ихластан үтәүчеләр булырга тиеш дип белдерә [15: 102-103]. Мөфти М.Солтановның нәсыйхәтнамәсе муллаларны мәчетне, җәмигъ намазын, халыкны яхшы эшләргә, хезмәт сөюгә, яңа һөнәрләр үзләштерүгә, әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен беренче планга куеп яшәргә өндәү урынына әйләндерергә, бер үк вакытта үзләренә дә бар яктан мәхәллә халкына үрнәк булырга өнди. Оренбург мөфтие фәтвасының, мөрәҗәгатенең, имамнарга тәэсире гаҗәеп зур була. Беренче тапкыр мөфти мөселман җәмгыятенең җитәкчесе буларак чыгыш ясый, мәхәлләләрдә социаль тормышны оештыруда һәрбер мөселманның, балаларны укытуда һәм тәрбияләүдә һәрбер ата кешенең үз алдында торган бурычын үтәүнең мөһимлеген ассызыклый, тормышта очраган тискәре күренешләрне җиңү мәхәллә халкының, бигрәк тә дин әһелләренең, үзләреннән тора дигән фикер уздыра.

Мөфти М.Солтанов 1898 елның 25 августында шәһәр имамнарына махсус нәсыйхәтнамә белән мөрәҗәгать итә. Ул, тагын да кыюланып, имамнар мөселманнар арасында алдынгы фикер таратырга тырышырга тиеш дигән сүзләрне ачыктан-ачык сөйли. Биредә дә башта игътибар бүгенге дин әһелләренең Мөхәммәд пәйгамбәр һәм дин галимнәренең эшләрен дәвам итүчеләр икәнлегенә, аларның тырышлыгы халыкның әхлагында һәм рухи тормышында чагылыш табуга, шуңардан чыгып кына эш нәтиҗәләрен билгеләп булуга юнәлтелә. Халкыбыз арасындагы наданлык, ялкаулык, эшсезлек, һөнәрсезлек, кирәгеннән артык фәкыйрьлек, артык иркенлектә гомер кичерүләр арасындагы угрылык, исерткеч эчү, фәхеш кәсепләре һәм башка начар күренешләр пәйда булуына ачынып, мөфти, «әгәр эшебез бу юлдан китсә, алдагы көнебез куркынычлыдыр», дигән нәтиҗә ясый [15: 118-119]. Халыкны тугры юлга өндәү сезнең эшегездер дип, имамнарга һәр җәмигъта, һич булмаса ике җәмигъка бер тапкыр гүзәл вәгазьне төркичә, мөмкин кадәрле һәркем аңларлык итеп әйтергә, күбрәк Коръәннән һәм хәдисләрдән мисаллар китереп, заманга һәм халык күңеленә туры килә торган сүзләр сөйләргә кирәклеген искәртә. Вәгазьләрегезнең ике яки өчесен безгә дә җибәрегез, заманыбызга муафыйк һәм мөселман кардәшләребезгә файдалы булганнарын туплап, вәгазьләр китабы эшләрбез, дип белдерә [11: 150-154; 15: 118-120].

Мөфтинең нәсыйхәтнамәләре кадимче белән җәдитче муллалар арасында башланган җомга хөтбәсе турында бәхәсне көчәйтеп җибәрә, бу өлкәдә җәдитчеләр файдасына, ягъни аны туган телдә сөйләү кирәклеге турындагы фикер ныгытыла, ә XX гасыр башында кайбер имамнар үзләре хөтбә

үрнәкләрен бастыралар [16: 118-120; 17: 181-184].

Мөфти М.Солтанов рөхсәте, казый Хәсәнгата Габәши инициативасы һәм Ризаэтдин Фәхретдин ярдәме-тырышлыгы белән 1898 елның 6 гыйнварында Уфа шәһәрендә җыелыш уздырыла. Анда «Ислахый мәктәб вә нәшери мәгарифе мөслимин» («Мөселманнарның төрки телен, мәктәп эшләрен һәм уку-укыту китапларын бастыруны яңарту») исемле беренче гомум милли мәсьәләләр белән шөгыльләнә торган иҗтимагый оешма төзү карары кабул ителә. Оешма үз өстенә төрки тел һәм графикасы өлкәсендәге реформаларны әзерләү һәм тиз арада уздыру, мәктәп программаларын эшләү, яңа дәреслекләр, гыйлемгә, төрле һөнәрләр алырга өндәгән гади халык аңлый торган телдә китаплар язу һәм бастыру бурычын куя [14: 113–114, 125–127, 139-141].

Х. Габәши һәм Р. Фәхретдин, катнашучылар исемлеген барлап, тикшереләчәк мәсьәләләрне ачыклап, 15–17 нче июнь көннәренә Уфа шәһәрендә «Ислахый мәктәб вә нәшери мәгарифе мөслимин» иҗтимагый оешмасының җыелышын уздыралар. Ризаэтдин Фәхретдин бу вакыйга уңаеннан русча укыган зыялыларның, Истанбулда белем алган шәкертләрнең, Бохарада торып кайткан муллаларның, учительләр белән карт хәлфәләрнең, студентлар белән сәүдәгәрләрнең, берләшеп, милли эш эшләргә актив катнашуына зур өметләрен белдерә [14: 114].

Казан, Оренбург, Троицк, Петропавловск, Семипалат һәм башка татар шәһәр җәмгыятьләре вәкилләре: әдипләр, мөхәррирләр, яңа фикерле имамнар, мөдәррисләр, мөгаллимнәр, педагоглар, чалмалы гимназистлар, студентлар – һәммәсе 30 кеше җыела. Алар арасында Мәхкамә-и шәргыянең казыйлары Ризаэтдин Фахретдин, Хәсәнгата Габәши, Гыйниятулла Капкаев, Уфа шәһәре ахуны Хәйрулла Госманов, Казаннан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисе Галимҗан Баруди, яшь булуына карамастан, мөгаллим, мөхәррир, педагог буларак шөһрәт алган Әхмәтһади Максуди, Казанның Иске Татар бистәсе мәдрәсәләрендә рус теле укытучысы Шакирҗан Таһиров, Самара губернасы Бөгелмә өязеннән ахун Гыйльман Кәрими һәм аның улы мөгаллим Фатих Кәрими, Бозаулык (Бузулук) шәһәреннән мөгаллим Галиәсгар Гафуров, Оренбургтан беренче дәрәҗәдәге сәүдәгәр Габделгани Хөсәенев, Оренбург «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллиме Габдеррәхим Дәминов , Оренбург губернасы Сәгыйд бистәсеннән Гомәр хәлфә Дәүләтъяров, данлыклы Буби мәдрәсәсе мөдәррисе Фәйзи Нигъмәтуллин, Орск шәһәре мәдрәсәсе мөдәррисе Әхмәтфаиз Даудов, Уфадан дәгъва вәкиле Әбүсәгыйть Әхтәмев, Саратовтан мөгаллим һәм имам Садыйк әфәнде, юрист булырга укучы студент Искәндәр Солтанов, студент Дәүләтгильдиев һ.б. [18: 39-41]. Мөфти М.Солтанов, җыелыш башланырга 2-3 көн кала, саклык йөзеннән, шәһәрдән дачасына ял итәргә китеп бара, шуның белән ул бу чарага үзенең катнашы булмавын күрсәтергә омтыла [14: 113].

Җыелышта берничә зур мәсьәлә тикшерелә һәм аларның һәрберсе буенча карар кабул ителә. Утырыш карарларының проектларын Х.Габәши әзерли. Карарлар тавышка куелып раслана, күбәйтелеп, һәр катнашкан кешегә бирелә. Сөйләшүләр, бәхәсләшүләр барышында төрки кавемнең киләчәге, бурычлары, алгарышны тәэмин итү өчен төп юнәлешләр һәм проектлар, аларны тормышка ашыручылар билгеләнә.

Имамнар һәм зыялылар, беренче бурыч итеп, дин һәм гыйлемнең нигезләрен халык телендә коруны билгелиләр. Алар «Русия эчендәге мөселманнар барчамыз төрек ыругы кавеме төркимез», «телемез дә төркидер», дип белдерәләр. Барча халыкка аңлашылырлык китаплар «үз телемез төрки вә казан шивәсе илә язылыр», дип тә өстиләр. Бу юллар XIX гасыр азагында татар шәһәр җәмгыятьләре алдынгы вәкилләренең милли үзаңнары буенча үзләрен «татар» дип түгел, «төрки» кавем дип санауларын, ә гади халык аңлашылырлык язу теле итеп «казан шивәсен» куллануны тәгаенләвен ачык күрсәтә. Ягъни Казанда, язылачак китапларга үрнәк, өлге булып, К.Насыйриның китаплары кебек басмалар торырга тиеш дигән мәгънә аермачык чагыла.

Халыкның илдә һәм дөньяда барган үзгәрешләр турында мәгълүматын киңәйтү, милекләрен арттыру, тормыш-көнкүрешләрен яхшырту һәм алга җибәрү максатларын куйган китапларны, гыйлем-мәгърифәт белән сугарып, төрле һөнәрләр турында «җиңел, саф, үз төрки телебездә», гади халык та, яшь шәкертләр дә укырлык, аңларлык итеп язып тарату бурычы куела. Җыелышта китапларны туган телдә, гади халык телендә язу кирәклеге турында карар һәм кайбер язу кагыйдәләре кабул ителә, төрки телнең морфологиясе һәм синтаксисы Каюм Насыйриның, Хөсәен Фәезхановның фәнни

хезмәтләре нигезендә язылыр дип белдерелә [18: 33-34].

Икенче кичекмәстән хәл ителергә тиешле мәсьәлә дип, дүртьеллык җәдит ибтидаи (башлангыч) мәктәбен, аның укыту программаларын төзү кирәклеген атыйлар. Моңарчы тупланган уку-укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп һәм үзара килешеп, җыелышта катнашучы мөгаллимнәр һәм мөдәррисләр һәр сыйныфта укытылачак предметларның исемлеген төзиләр. Алар арасында намаз шартлары, дини предметлар белән беррәттән, кыскача география һәм төрки кавеме тарихы, хисап, геометрия нигезләре кебек дөньяви фәннәр каралган [18: 36-37]. Ләкин рус телен укыту программага кертелмәгән, ягъни башлангыч белемне төрки кавем укучылары фәкать туган телләрендә алырга тиеш дигән фикер уздырылган.

Җыелышта, шулай ук ибтидаи мәктәп өчен кирәк булган ун дәреслек тәгаенләнеп, аларның авторлары билгеләнә. Авторлар буларак җыелышта катнашучылар да, шулай ук Уфага килми калган педагог, мәгърифәтчеләрнең дә исемнәре атала. «Ана телемез улган төрки телнең» синтаксис китабын моңарчы чыккан басмаларга нигезләнеп эшләү Фатих Кәримигә тапшырыла. Татар телендә уку китабы өчен әхлак турында һәм башка файдалы мәгълүматларны эченә алган бер китап язу Буби мәдрәсәсе мөдәррисе Фәйзи Нигъмәтуллинга кушыла. Хисап буенча дәреслек авторы итеп Шакирҗан Таһиров тәгаенләнә, төрки кавемнең тарихын язу «Төрек ыруглары» (Казан, «Милләт» матбагасы, 1897) исемле дәреслек авторы Хәсәнгата Габәшигә йөкләнә. Әхлак тәрбиясенә багышланган дәреслекне язу Әхмәтфаиз Даудовка, инша (сочинение) кагыйдәләре турында уку әсбабын төзү Галимҗан Барудига тапшырыла. Мөгаллимнәргә юл күрсәтүче дәреслек авторлары итеп Казан татар укытучылар мәктәбе инспекторы Шаһбазгәрәй Әхмәрев һәм Фасыйхетдин Мөхетдинев билгеләнә, геометрия буенча уку ярдәмлеге эшләү Габдеррәхим әфәндегә, орфография кагыйдәләрен җыю һәм теркәп бастырып чыгару Әхмәдһади Максудига тапшырыла. Ул татар теле грамматикасы белән татар теле сүзлеген һәм, гади халык аңларлык итеп, география дәреслеген дә язарга була. Троицкий шәһәре мәктәпләрендә кулланыла торган география дәреслеген барлык мәктәпләрдә файдалану турында килешенә [18: 38].

Шулай итеп, мәктәп программаларын төзү, халык арасында кирәкле китаплар язу һәм таратуны җәмгыять белән бергәләп башкару фарыз дип табыла [16: 182-183]. Һәркем әзерлеге, мөмкинлеге һәм көче җиткән кадәр «кавемебез вә милләтебезгә хезмәт күрсәтсен!» дигән карарны җыелышта катнашучылар үзләренә кабул итеп таралышалар. Соңгы утырышларның берсендә бер еллык хезмәтләрне, ел саен җыелып, җәмгыятькә тәкъдим итәргә дигән фикер әйтелә. Моңарчы «Тәрҗеман-Переводчик» газетасы тирәсендә тупланып, андагы мәкаләләрне укып, рухланып, фикер туплаган һәм фикердәшләр тапкан җәдитчеләр Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыядә, аның казыйлары йөзендә тагын бер фикри һәм оештыру үзәгенә ия булалар. Иң мөһиме: шушы вакыттан башлап, мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган китапчыклар һәм уку әсбаплары гади халык телендә – «төрки телдә» – киң укучылар аудиториясен күздә тотып языла башлый. 4-5 ел вакыт эчендә милли башлангыч мәктәпкә кирәк булган уку әсбаплары да пәйда була, нәтиҗәдә, XX гасыр башында татарларда һәм башкортларда тулы канлы башлангыч җәдит мәктәпләр саны күбәя.

Шундый зур рухи күтәренкелек шартларында үткән җыелышның кабат уздырылмау сәбәбен Х.Габәши Уфа шәһәрендәге искелек яклы имамнарның һәм, бигрәк тә, Мәхкамә-и шәргыя казые ахун Гыйниятулла Капкаевның баштан ук бу чараны булдырмау өчен тырышуы, максатына ирешмәгәч, кабул ителгән карарларны карага буяп, шәһәр мөселманнарына куркыныч сурәттә күрсәтеп, кадимче фикердәшләре белән «кара агитацияләр» ясавы белән бәйләп аңлата. Планлаштырылган проектларны тормышка ашыру 1898 елда әле уңышлы дәвам итә. Әмма җыелышның рухи җитәкчесе булып танылу алган Х.Габәши, Уфа шәһәре кадимчеләренең интригаларына, төрле яла ягуларына, зәһәрле сүзләренә түзә алмыйча, авыруга сабышып, табибларның киңәше белән, уку-язуны туктатып торырга мәҗбүр була. Ул, вакыты тәмамланганчы ук, тәмам авырып, 1899 елның 13 февралендә казыйлык вазифасыннан баш тартып, гаиләсен алып, кыш уртасында туган авылына кайтып китә. Х.Габәши 1928 елда язган истәлекләрендә, бераз үпкәсен белдереп, фикердәше казый Р.Фәхретдиннең, үзенең хатыйб (оратор) түгеллеген һәм тавышы зәгыйфьлекне сылтау итеп, һәрвакыттагыча,

көрәшүдән читтә калуын, кабат кабинетына кереп бикләнеп, язу эшенә өстенлек бирүен, нәтиҗәдә 1899 елда Уфада, Махкәмә-и шәргыядә, җәмгыятьнең икенче җыелышын уздыру мәсьәләсе белән шөгыльләнүче шәхес калмавын хәбәр итә [19: 44-45]. Р.Фәхретдин исә башкарак фикер әйтә: «Чиновникларның гадәттән тыш тикшереп торулары сәбәбеннән ошбу җәмгыять моннан соң кабат җыелмады, һәм идарәсе һичбер эш эшләмәде» [14: 114]. Хаклык кайдадыр уртада, күрәсең. Чөнки Х.Габәши 1905 елда кабат казыйлык вазифаларына керешкәч, җәмгыять эшләп китми. Күрәсең, ул вакытка беренче куелган максатларның күбесе үтәлгән булып, Х.Габәшине исә башка иҗтимагый һәм сәяси мәсьәләләр кызыксындырган. Р.Фәхретдин Гани байның үлеменә 10 ел тулу уңаеннан язган истәлекләрендә, бу җәмгыять рәсми статуста торгызылган очракта, аның мәдәният, тел һәм мәгариф өлкәсендәге реформаларны координацияләү өлкәсендә кирәкле булуын искәртә [14: 113].

Җәмгыять җыелмый дип, эш һич кенә дә туктап калмый, бик күпләр үзләренә алган йөкләмәләрне намус эше санап, акча табып, аларны тормышка ашыралар. 1898 нче елда Р.Фәхретдин, башлаган хезмәтен дәвам итеп, гади халык телендә язылган «Тәрбияле ана» [20], «Тәрбияле ата» [21], «Тәрбияле бала» [22] исемле зур булмаган китаплар нәшер итә. Үгет-нәсыйхәткә корылган сериясенең дәвамы булган «Тәрбияле хатын» [23], «Шәкертлек әдәбе» [24] китапчыклары 1899 елны укучылар кулына барып ирешә.

Р.Фәхретдин 1899 елда, кадимчеләрнең нахак сүзләреннән саклану максатында, «Габдулла улы Гафил» псевдонимы белән «Сәлимә, яки Гыйффәт» исемле әсәрен бастыра [25]. Повестьның баш герое – шәкерт, үзенең кадими мәдрәсәдә укучы иптәшләренә мөрәҗәгать итеп, безнең җитәкчеләребез ислам дине фәннәрен дә, бүгенге дөнья фәлсәфәсен дә яхшы белүчеләр булырга тиеш дигән таләп куя. Милләтнең алгарышы белем таратуда, һөнәрләр һәм сәнәгать үсешендә дип игълан итә.

Җыелышта сәүдәгәр Габделгани Хөсәенов белән танышканнан соң әтисе белән авылдан Оренбург шәһәренә күченгән Фатыйх Кәрими [14: 140] «Мохтасар җәгърафия» уку китабын язып бастыра [26]. Аның шулай ук 1899 елны дөнья күргән «Бер шәкерт илә бер студент» исемле әсәре мөселман җәмәгатьчелегендә зур шау-шу тудыра [27]. Хикәя авторы, рус һәм татар укучыларын чагыштырып, европача белем алуның тормышта дини схоластик белемгә караганда өстенлекләрен раслый, кадимчеләр дәлилләренең дөрес түгеллеген күрсәтә. Ф.Кәрими, «Ислахый мәктәб вә нәшери мәгарифе мөслимин» иҗтимагый оешмасы карарларын күздә тотып, 1900 елда Казан татар укытучылар мәктәбе инспекторы Шаһбазгәрәй Әхмәров үлеп киткәч, башлангыч мәктәп укытучылар өчен гаять кирәкле булган «Мөгаллим вә мөрәббиләргә рәһнамә» («Мөгаллимнәргә һәм тәрбиячеләргә юл күрсәтүче») исемле методик ярдәмлеген яза [28].

Казанда Ибраһим Терегулов кыскача татар синтаксисы кулланмасын яза [29]. Уку әсбаплары язу өлкәсендә Әхмәтһади Максуди да нәтиҗәле хезмәтен дәвам итә [30; 31].

1899 елның маенда алдынгы татар җәмәгатьчелеге җыелышында Оренбург сәүдәгәре Габделгани Хөсәенов үз хисабына Каргалыда ир туганнары белән бергә төзеткән 9 мәчет каршындагы дүрт сыйныфлы җәдит мәктәптә укытучылар әзерләү курслары ачу теләген белдерә. Бу курслар 1899-1901 елларда, полиция тарафыннан ябылганчы, уңышлы эшләп килә. Җәйге чорда ел саен Казан, Оренбург, Уфа, Самара, Вятка, Саратов, Пенза, Пермь, Тубыл һәм башка губерна-өлкәләрдән (барлыгы 30 артык) килгән 210 мөгаллим [14: 141 149, 218] яңа ысул белән укырга өйрәтү методикасын үзләштерә, шулай ук махсус чакыртылган, күбесе чит илләрдә укыган атаклы мөгаллимнәрдән тәрбия, математика нигезләре, инша язу осталыгы, орфография, синтаксис, тарих, география, тәүхид, хәдисләр, тәфсир буенча дәресләр тыңлый. Киңрәк алсак, Габделгани бай 1897-190 елларда үз хисабына Оренбург губернасында 100 гә якын җәдит мәктәбе һәм 20 дән артык кызлар уку йортлары ача [32: 80, 82]. Алардагы уку-укыту эшләрен күзәтеп бару, вакытында хезмәт хакы түләү өчен махсус кеше тота.

Мөселман җәмгыятенең кайбер укыту һәм мәдәни проблемаларын хәл итүне максат итеп куйган җәмгыять оешу Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя казыйларын яңа сыйфатта ача: аларны дәүләти дин эшләрен күзәтүче оешма гына түгел, ә алдынгы төрки-мөселман милләтен формалаштыру, яңарыш, яңа ысул белән укыту, гомумән, мөселманнар арасында дөньяви белем, яңалык таралсын өчен тырышучылар әйдәманы дип расларга

мөмкинлек бирә. Бу очракта казыйлар Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыянең төбәкләр белән дистә еллар дәвамында ныгыган элемтәләрен һәм абруен файдаланып, алдынгы карашлы мөселманнарны чакырып, олы җыелыш оештыралар. XIX гасыр азагында «төрки» исеме белән билгеләнгән, Идел буе, Урал төбәге һәм Көнбатыш Себердә көн күргән мөселман зыялыларны туплап, фикерләшеп, шәһәр җәмгыятьләрендә барган яңарышка яңа импульс бирәләр. 1905 елда оешкан, гомуммөселман проблемаларын көн тәртибенә куйган «Иттифак әл-мөслимин» партиясе барлыкка килгәнче, уку-укыту, мәдәни һәм балаларга милли тәрбия һәм белем бирүне Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя казыйлары оештырган җәмгыять беренче тапкыр милләткүләм комплекслы хәл итәргә омтыла. Х.Габәшинең Уфадан китүе җәмгыятьнең эшен туктатса да, аның карарлары аерым җәдитчеләр тарафынаннан тормышка ашырыла. Мөфти М. Солтановның 1897 һәм 1898 елларда мөселман җәмгыятьләрендә заманга хас үзгәрешләр таләп итеп язган нәсыйхәтнамәләре дә мөселманнар яңарышы үзәгенә әверелгән Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыянең иҗтимагый мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән эшчәнлегенең иң югары ноктасы буларак бәяләнә ала.

**Әдәбият**


1. *Загидуллин И.К.* Предисловие // Оренбургское магометанское духовное собрание и духовное развитие татарского народа в XVIII – начале XX вв. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2001. С.3-11.
2. *Гарипова Р.Р.* Политика брака и развода у мусульман Волго-Уральского региона в имперской России конца XIX – начала XX века // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. Сб. статей. Вып. 2. Материалы Всероссийской научной конференции «Исторический опыт этноконфессионального взаимодействия в Среднем Поволжье и Приуралье (XVI – начало XX вв.)» (Казань, 5–6 октября 2011 г.). Казань, 2011. С.169-176.
3. Российский государственный исторический архив. Ф.821. Оп.8. Д.1074. Л.5–7.
4. Российский государственный исторический архив. Ф.821. Оп.8. Д. 800. Л.242-245.
5. Полное собрание законов Российской империи. Собр.3-е. Т.8. №5419.
6. Полное собрание законов Российской империи. Собр.3-е. Т.10. №7120.
7. Казанский телеграф. 1896. 30 мая.
8. Полное собрание законов Российской империи. Собр.3-е. Т.10. №6512.
9. *Загидуллин И.К.* Деятельность Р.Фахреддина в Оренбургском магометанском духовном собрании (1891-1906 гг.) // Научный Татарстан. 2009. №2. С.146-158.
10. *Габәши Х.* Минем тәрҗемәи хәлем. Басмага Р.Миңнуллин әзерләде // Гасырлар авазы-Эхо веков. 1997. №3/4. Б.194-204.
11. Сборник циркуляров и иных руководящих распоряжений Оренбургского магометанского духовного собрания. 1836-1903 гг. / Сост. Р.Фахрутдинов. Уфа: губерн. типогр., 1905. 225 с.
12. Тарҗеман-Переводчик. 1887. № 2. 11 января.
13. *Габдерәшит И.* Бөгрәделек көндәлеге./ Кереш сүз, факсимиле һәм гарәп транскрипциясе Ә.Бостанов, татарчага тәрҗемәсе Д.Гыйльметдинов. Казан, 2013. 190 б.
14. Гани бай: Гани байга 160 яшь тулу мөнәсәбәте белән (1839-1902) / Төз. М.Ф.Рахимкулова. Оренбург, 1998. 259 б.
15. Мәҗмуга. Җәмгыять шәргыя Ырынбургыя, яңа мөфти алиәссәләм тарафындан нәшер улынмыш указ һәм нәсихәтләр, ушындук төрле хосусда язылмыш тәдбир һәм назәмнәрнең төркичә тәрҗемәләре җыелмышдыр. Имамнар, яңа имам улачаклар өчен кирәкле бер әсәрдер. Уфа: Губернский типография, 1905.189 б.
16. *Мараш И.* Религиозное обновление в тюркском мире (1850–1917). Пер. с турецкого. Казань: Изд–во «Иман», 2005. 199 с.
17. *Загидуллин И.К.* Исламские инстиуты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 416 с.
18. *Кәрими Ф.* Аннан-буннан. Оренбург: Кәримев-Хөсәенев, 1907. 90 б.
19. *Кәрими Ф.* Мохтәсар җәгърафия. Казан: Университет табыгханәсе, 1899. 48 б.
20. *Кәрими Ф.* Бер шәкерт илә бер студент. Казан: Б.Л.Домбровский матбагасы, 1899. 40 б.
21. *Кәрими М.* Мөгаллим вә мөрәббиләргә рәһнамә. 1 җөзьә. Оренбург: М.-Ф. Кәрими матбагасы,1902. 41 б.
22. *Кәрими М.* Мөгаллим вә мөрәббиләргә рәһнамә 2 җөзьә. Оренбург: М.-Ф. Кәрими матбагасы, 1902. 65 б.
23. *Габәши Х.* Тәрҗемәи халем. Солабаш, 1928. 33 б. // Казан федераль университеты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге. 1542 т.
24. *Фәхретдин Р.* Тәрбияле ана. Ачык ана телемездә язылмыштыр:«Гыйльме әхлак»тан 1 җөзьә. Казан: Казан университеты матбагасы, 1898. 16 б.
25. *Фәхретдин Р.* Тәрбияле ата: Төрки таныган балалар аталарына укып күрсәтмәк өчен. Казан, 1898. 16 б.
26. *Фәхретдин Р.* Тәрбияле бала. «Гыйльме әхлак»тан 1 җөзьә. Казан: М.Чиркова варислары матбагасы, 1898. 16 б.

27. *Фәхретдин Р.* Тәрбияле хатын: Һәрбер өйдә һәрбер хатын кулында бу китапның бер данәсе булырга тиеш. Казан, 1899. 22 б.
28. *Фәхретдин Р.* Шәкертлек әдәбе. «Гыйльме әхлак»тан 5 җөзьэ. Казан, 1899. 47 б.
29. *Габдулла улы Гафил.* Сәлимә, яки Гыйффәт. Казан, 1899. 80 б.
30. *Терегулов И.* Татар нәхүсенең мохтәсары. Казан, 1901. 53 б.
31. *Максуди Ә.* Гакаид Исламия. Ибтидаинең 2-нче сыйныфлары өчен. Казан, 1889. 48 б.
32. *Максуди Ә.* Шәригать исламиянең әхкяме гамалиясе. Казан, 1899. 72 б.
33. *Шайдуллина Р.Р.* Торгово-предпринимательская и благотворительная деятельность братьев Хусаиновых (вторая половина XIX – начало XX вв.): Дис. … канд. ист. наук. Казань, 2010. 212 с.

---

# ОРЕНБУРГСКОЕ МАГОМЕТАНСКОЕ ДУХОВНОЕ СОБРАНИЕ – ЦЕНТР РЕФОРМ МУСУЛЬМАНСКОГО СООБЩЕСТВА КОНЦА XIX ВЕКА

**Ильдус Котдусович Загидуллин,**
Институт истории имени Ш.Марджани Академии наук Республики Татарстан,
Россия, 420014, г.Казань, Кремль, подъезд 5,
zagik63@mail.ru.

Оренбургское магометанское духовное собрание – правительственное учреждение, курировавшее исламские институты Поволжья, Приуралья и Сибири и являвшееся головным звеном религиозно-культурной автономии мусульман, в конце XIX в. стало позиционирвать себя как центр, транслирующий идеи обновления общественной жизни мусульманского сообщества.

Муфтий М.Султанов, составив в 1897 г. фетву к имамам и преподавателям конфессиональных школ о необходимости превращения приходов и семей в самодостаточные в экономическом отношении ячейки по организации религиозной практики, системы обучения и нравственного воспитания подрастающего поколения, призвал имамов читать проповеди с минабара мечети на родном, понятном для прихожан языке, побуждать их к социальной активности, овладению новыми профессиями и знаниями, преподавать в школах востребованные учебные предметы. В его фетве 1898 года, адресованной городским имамам, впервые говорится о необходимости пропаганды прогресса, позитивных изменений в мусульманском обществе.

Весьма значительным событием в жизни мусульманского сообщества региона стало учреждение в 1898 г. в Уфе заседателями ОМДС Х.Габаши и Р.Фахретдиновым незарегистрированного общества и проведение съезда, на котором было принято решение о печатании популярных и полезных книг для населения на родном языке, на «тюрки», были утверждены некоторые правила правописания, разработана сетка предметов для четырехлетней джадидской национальной начальной школы, списки необходимых учебных пособий и их авторов-составителей.

Фетвы муфтия М.Султанова 1897 и 1898 гг. с требованием изменений в жизни общин, соответствующих требованиям времени, и проведение съезда общества, призванного решать общенациональные проблемы, стали высшей точкой в деятельности ставшего идеологом модернизации мусульманского общества ОМДС, направленной на решение общественных проблем мусульман. В результате в начале XX в. получила развитие полноценная, в целом обеспеченная учебными пособиями начальная джадидская школа, расширилось издание научно-популярных книг на татарском языке.

**Ключевые слова:** Оренбургское магометанское духовное собрание, муфтий М.Султанов, Х.Габаши, новомедная начальная школа, джадидизм, модернизация, имамы.